

«Мәктәп музее» - 2022 Ботенроссия проектынын 8 нче топ бурычы «Мәктәп музеен vзгәртv» номинациясе. Дубенка районы «Кочкуровская СОШ имени Народного учителя СССР С.И.Дергачёва» мәктәбендәге «Точка роста» мәгариф базасында Наталия Корнишина житәк-челегендә Медиацентр эшли.
- «Мәктәп музеен vзгәртv» номина-циясендәге биремне укыгач, без вакытлы кvргәзмә концепциясе турында уйладык. Баш мие һожvме нәтижәсендә кvргәзмә идеясе эшләнелде, партнеры, урыны, вакыты билгеләнде. Гамәлгә ашыруга керештек, - ди Медиаvзәк житәкчесе Наталия Корнишина.

- Дубенка районы Ломаты авылынын краеведение музее директоры белән шалтыратышып, хезмәттәшлек турында килештек. Экспонатларны сайлап алу очен татар мәдәнияте музеена экскурсия оештырылды. Музей житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева безнен очен кызыклы экскурсия vткәрде. Бередә авылнын тарихы, халкы, әдәбияты, мәдәнияты чагылган экспонатлар урнаштырылган. Гореф-гадәтләрне саклаган олеше дә бар. Ул татар халык ашларын пешереп, бергәләп чәй эчv белән эчтәлекле экскурсияне тәмамлады. Кунаклар «колак» һәм «алка» милли татар ризык-ларыннан авыз иттеләр. Балаларда Ломат авылы татарларынын тарихы һәм мәдәнияте белән аралашудан кvп тәэсирләр алып кайттылар.
Ә Ломат авылы музее житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева бу проект турында болай ди: «26 апрельдә Ломаты авылынын жирле тарих музеена кvрше Корчуровский урта мәктәбе укучылары, Н.А.Корнишина һәм укытучылары Л.В.Киселева житәкчелегендә килеп, безнен авыл тарихын дәртләнеп тынладылар. Музей экспонатлары аша Ломат авылы борынгы мәдәният һәм тормыш һәйкәлләренә кагылдык. Милли татар костюмнары һәм традицияләре әйберләрен кvрсәттем һәм килеп чыгышлары тарихын сойләдем. Әрзә милләтле укучылар сораулар бирделәр һәм безнен традицияләрне vзләренеке белән чагыштырдылар.
Мин аларга шулай ук безнен Боек Ватан сугышы ветераннары турында да сойләдем. Экскурсия ахырында, традицияләребез буенча, «колак» һәм «алка» тәмле милли татар ризыкларыбыз белән чишмә суында кайнатылган кайнар чәй эчv безнен гадәткә кергән. Балаларга кыздырылган «колак»лар бик ошады. Кызлар бу ризыкларнын рецептын

сорадылар һәм ойдә мондый камыр ризыклары пешерергә теләделәр. Шулай итеп, биредә укучылар татар халкы тарихы белән таныштылар, милли сәнгать әйберләренен матурлыгын кvрделәр. Рухи-әхлакый тәрбия бирv, патриотик хисләр формалаштыру, кvрше халыкларнын мәдәни кыйммәтләренә кызыксыну тәрбияләнде. Барысына да бик ошады», - дип сvзен йомгаклады Ломат авылы музее житәкчесе һәм экскурсияне алып баручы Мәзидә Якуб кызы Муракаева.



Дубенка районы Кочкурово дигән әрзә авылы янында районда бердән-бер татар Ломат авылы урнашкан. Ломат балалары Кочкурово авылы мәктәбендә белем ала. Ике халыкнын декоратив-кулланма сәнгате экспонатларын кvрсәтv аша vзара хөрмәт һәм дуслык тәрбияләнә бу экскурсияләрдә. Әйтеп китик, кvргәзмәне оештыручылар булып Н.Корнишина житәкчелегендә «Затея» командасы әгъзалары: Д.Еремкина, П.Наумкина, А.Кочетков, С.Мусина тора. Кvргәзмә Ломаты авылынын татар мәдәнияте музее белән партнерлыкта әзерләнә. Әрзә мәдәнияте әйберләрен Кочкурово мәктәбе музееннан алалар. Хәзер алар «Ике халык – бер Ватан» вакытлы кvргәзмә аша әрзә һәм татар халыкларынын мәдәнияте һәм традицияләре белән танышалар.
Әйтеп китәргә кирәк, бәйрәм ялларында һәм яз башы буена музейга халык килде. Кем Ломат авылы тарихы, халкы, гореф-гадәтләрен искә тошерде (рәсемдә Альфинур Няим кызы Хамитова белән Мязидә Якуб кызы Муракаева), кем борынгы бабалары турында мәгълумат алып килде. Халык онытмый vзенен кече Ватаны тарихын.

**Наилә НАСЫРОВА**